КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 13 июль г.Казань № 491

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елда социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча мәгълүмат ресурсы турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 15 февраль, 81 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«№ 1-РГ (еллык) «Йөрү максатлары буенча гражданнарны урнаштыру һәм туристлык хезмәте күрсәтүләрне яхшырту ысуллары турында белешмәләр».»;

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2017 елда мәгълүмат ресурсын (мәгълүматлар базасын) № 1-РГ (еллык) «Йөрү максатлары буенча гражданнарны урнаштыру һәм туристлык хезмәте күрсәтүләрне яхшырту ысуллары турында белешмәләр» республика дәүләт статистика күзәтүе формасы нигезендә формалаштырырга.»;

карарга № 1-РГ (еллык) «Йөрү максатлары буенча гражданнарны урнаштыру һәм туристлык хезмәте күрсәтүләрне яхшырту ысуллары турында белешмәләр» республика дәүләт статистика күзәтүе формасын өстәргә (теркәлгән);

әлеге карар белән расланган, Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты «Мәгълүмати статистик ресурс» автоматлаштырылган системасында яки https://intra.tatar.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәтенең эчке контурында «Ачык Татарстан» мәгълүмат порталының «Ведомстволар хисаплары» бердәм дәүләт хисаплылык системасында 2017 елда дәүләт хакимияте һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары өчен урнаштыра торган мәгълүмати материаллар исемлегендә:

2 бүлекнең 2.7 пунктындагы 5 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25.04.2017»;

3 бүлектә:

3.4 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кече эшмәкәрлекне исәпкә алып, хезмәткәрләрнең уртача исемлек саны һәм уртача айлык эш хакы турында мәгълүматлар» таблица материалы»;

3.5 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эре һәм урта предприятиеләр хезмәткәрләренең уртача исемлек саны һәм уртача айлык эш хакы турында мәгълүматлар» таблица материалы»;

3.9 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бюджет оешмалары хезмәткәрләренең уртача исемлек саны һәм уртача айлык эш хакы турында мәгълүматлар» таблица материалы»;

7 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 7.6 пункт өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «7.6. | «Мәгълүмат һәм коммуникация технологияләре өлкәсендә эшчәнлекләрен тормышка ашыручы предприятиеләр турында мәгълүматлар» таблица материалы | республика | квартал саен | 26.06.2017 (2017 елның гыйнвар – марты өчен), 26.09.2017, 26.12.2017»; |

12 бүлекнең 12.5 пунктындагы 2 графага «*» астөшермә билгесен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле бүлек өстәргә:

«18. Хезмәт күрсәтүләр

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 18.1. | «Йөрү максатлары буенча гражданнарны урнаштыру һәм туристлык хезмәте күрсәтүләрне яхшырту ысуллары турында белешмәләр» таблица материалы | республика | елга бер тапкыр | 15.06.2017 (2016 ел өчен)»; |

әлеге карар белән расланган № 1-торак фонд-рег (еллык) «Торак фондны куллану һәм аны саклауны тәэмин итү турында мәгълүматлар» республика дәүләт статистика күзәтүе формасын яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән);

әлеге карар белән расланган № П-1 (АХ)-р (айлык) «Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм сату турында мәгълүматлар» республика дәүләт статистика күзәтүе формасын яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән);

әлеге карар белән расланган эшмәкәрлек мәсьәләләрен өйрәнү буенча анкетаны (бер тапкыр) яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән).

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 елда социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча мәгълүмат ресурсы турында һәм

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 14 гыйнвар, 11 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 12 сентябрь, 661 нче; 2014 ел, 23 декабрь, 1014 нче; 2015 ел, 30 апрель, 309 нчы, 2015 ел, 31 декабрь, 1038 нче; 2016 ел, 25 май, 350 нче; 2017 ел, 15 февраль, 81 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган № ПМ (квартал) «Кече эшмәкәрлек эшчәнлегенең төп күрсәткечләре турында мәгълүматлар» республика дәүләт статистика күзәтүе формасын яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән);

әлеге карар белән расланган № 1-бүлү (елга 1 тапкыр) «Хезмәткәрләр санын эш хакы күләме буенча бүлү турында мәгълүматлар» республика дәүләт статистика күзәтүе формасын яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин